Түбән Үрәс авыл җирлеге Советы

КАРАР

27.02.2023 ел №4

Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясындагы 3 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль Закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Түбән Үрәс Уставы нигезендә Түбән Үрәс Советы карар бирде:

1. Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләргә6

1) закон буенча да, васыять буенча да варислар юк икән, яки варисларның берсе дә мирас алырга хокуклы түгел яисә варисларның барысы да мирастан читләштерелгән, яки варисларның берсе дә мирасны кабул итмәгән, яки барлык варислар да варисларыннан баш тарткан һәм аларның берсе дә икенче варисның файдасына баш тартканын күрсәтмәгән икән, физик зат үлгәннән яки граждан процессуаль законнары белән билгеләнгән тәртиптә аны үлгән дип игълан иткәннән алып, өч еллык срок бетү;

2) салым салу объекты булып тора торган мөлкәткә милек хокукы туктатылганнан соң өч еллык срок бетү;

3) юкка чыгарылган җирле салымнарны һәм җыемнарны түләү бурычы барлыкка килгәннән соң өч еллык срок бетү.

2. «Җирле салымнар, пенялар һәм бу салымнар буенча штрафлар буенча бурычларны түләүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләре турында» 2020 елның 2 июлендэге 13 номерлы Түбән Үрәс авыл җирлеге карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында», Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://kukmor.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Түбән Үрәс авыл җирлеге территориясендәге мәгълүмат стендларында бастырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Түбән Үрәс авыл җирлеге Советы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

ТүбәнҮрәс авыл җирлек башлыгы В.Г.Сафаров